**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге Башкарма комитеты карары**

**17.07. 2017 ел** **№ 4**

**2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше программасын раслау турында**

“Россия Федерациясе җирле үзидарә оешмасының гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 –ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2014 елның 29 декабрендәге 456 –ФЗ номерлы Федераль закон, “Авыл җирлекләренең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше программасын раслау турында”гы 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә, “Муниципаль берәмлекләрнең транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше программасын эшләү турында”гы 2016 елның 6 июнендәге 326661 номерлы, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов Йөкләмәсе белән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге транспорт инфраструктурасының 2030 елга кадәр булган комплекслы үсеш программасын расларга;

2. Шушы карарны түбәндәге мәгълүмати стендларда урнашкан адреслар буенча халыкка таратырга:

- ТР Кама Тамагы муниципаль районы, Осинники п., Яшьләр урамы, 9А- йорты;

-ТР Кама Тамагы муниципаль районы, Осинники п., Лесная урамы, 2- йорт;

һәм Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтының Интернет челтәрендәге адресы: **http://msu.tatar.ru/admin.**

Осинники авыл җирлеге җитәкчесе Сәгдиев А.Х.

**2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше**

# ПРОГРАММАСЫ

ЭЧТӘЛЕК:

1. Программа паспорты
2. Гомуми белешмәләр
3. Җәмәгать транспорты
4. Урам-юл челтәре
5. Транспорт комплексын үстерү өстенлекләре
6. Урам-юл челтәрен оптимальләштерү
7. Транспорт өчен тукталыш һәм озак вакыт саклау урыны оештыру
8. Җәяүлеләр урамнары һәм велосипед өчен юллар системалары оештыру: мөмкинлекләре чикле затлар өчен барьерсыз мохит тәэмин итү

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше программасы**

# ПАСПОРТЫ

**Атамасы**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге транспорт инфраструктурасы системасының 2030 елга кадәр комплекслы үсеше программасы

**Муниципаль заказчы**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге Башкарма комитеты

**Программның урнашу урыны**

ТР Кама Тамагы муниципаль районы, Осинники п., Яшьләр урамы, 9А- йорты;

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге транспорт инфраструктурасы системасының 2030 елга кадәр комплекслы үсеше программасы түбәндәге документлар нигезендә эшләнгән:

- Россия Федерациясенең Шәһәр төзү кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 2014 елның 29 декабрендәге 456 –ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә;
- "Авыл җирлекләренең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше программасын раслау турында"гы 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә;
- "Муниципаль берәмлекләрнең транспорт инфраструктурасы системасының комплекслы үсеше программасын эшләү турында"гы 2016 елның 6 июнендәге 326661 номерлы, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов Йөкләмәсе белән;

Программа транспорт инфраструктурасын оештыру һәм үстерү, бу системаның эшләвенең ышанычлылыгын арттыру һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге кешеләренең яшәеше өчен уңайлы һәм куркынычсыз шартлар тудыру буенча беренче чираттагы чараларны үз эченә ала.

**Гомуми белешмәләр**

Түбәндәге муниципаль берәмлек Идел елгасының уң як ярында Татарстан Республикасының көнбатыш өлешендә урнашкан. Аның административ үзәге булып Осинники посёлогы тора. Осинниковское авыл җирлеге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге, Тәтеш урман хуҗалыгы һәм Кариле урманчылыгы белән чиктәш.

**Транспорт комплексы.**

**Тышкы транспорт**.

Җирлек территориясендә тышкы транспорт бер төр – автомобиль транспорты белән тәкъдим ителгән. Торак пунктында тышкы транспорт зур күләм (урын) алып тормый.

Җирлек аша бары тик бер төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлы үтә.
Төбәк әһәмиятендәге Тәмте – Улан автомобиль юлы Осинниковское авыл җирлеген Ульяновск трассасы белән бәйли.

Төбәк әһәмиятендәге Тәмте – Улан автомобиль юлы Осинниковское авыл җирлеген Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авылы белән бәйли.

Осинниковское авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларының озынлыгы якынча 2 километр тәшкил итә.

**Шул рәвешле, тышкы транспорт өлкәсендәге Программаның түбәндәге чаралары булачак:**

1.Муниципаль берәмлекнең территориаль планлаштыруындагы региональ һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын төзү һәм төзекләндерү буенча чараларын исәпкә алу (барлык вакыт аралыгында).

2.Автомобиль юлларының перспективалы төзелеше коридорларының резервта калдырылуын тәэмин итү (барлык вакыт аралыгында).

**Җәмәгать транспорты**.

Транспорт – йөк һәм пассажирларны ташу буенча халыкның һәм икътисадның барлык тармакларының мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүче, җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасындагы төрле төр азык-төлекне күчереп йөртүче, халыкны транспорт белән тәэмин итүче җирлекнең инфраструктурасының иң мөһим состав (тәшкил итүче) өлеше.

Транспортның тотрыклы һәм нәтиҗәле функциаләштерелүе (хәрәкәтләнүе) халыкның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерүдә кирәкле шарт булып тора. Осинниковское авыл җирлегендә автотранспорт предприятиесе юк.

Осинниковское авыл җирлеге белән район үзәген тоташтыручы регуляр автобус транспорты да хәзерге вакытта юк. Җирлектә максатчан хәрәкәт күпчелек шәхси автотранспортка һәм җәяүлеләргә туры килә.

**Урам-юл челтәре.**

Урам-юл челтәре торак пунктларның транспортлык, инженерлык һәм социаль инфраструктурасының төп элементы булып тора. Юл челтәрен һәм инфраструктура объектларын үстерү җирлекнең комплекслы үсешендә социаль әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Җирлектәге автомобиль юлларының шактый өлеше асфальтлы бетон катламга ия.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинниковское авыл җирлеге урам-юл челтәре характеристикасы

| № т./б. | Урам исеме | Ара ераклыгы, км | Транспорт юлы киңлеге, м | Урамда урнашкан объектлар |
|---|---|---|---|---|
| | **Осинники поселогы** | | | |
| 1 | Яшьләр урамы | 1,2 | 4 | Административ бина, торак сектор |
| 2 | Лесная урамы | 0,8 | 3 | Кибет, АМЙ, китапханә, торак сектор |

**Транспорт комплексының үсеш өстенлекләре**

Муниципаль берәмлекнең транспорт комплексының төп өстенлекләре:
- гамәлдәге урам-юл челтәренең юл катламының ремонты һәм реконструкцияләнүе;
- гамәлдәге грунтлы юлларда каты өслекле юллар төзелеше булырга тиеш.

Муниципаль берәмлекнең территориясенең транспорт үсеше төрле хакимият дәрәҗәсенең: федераль, региональ, муниципаль хакимиятләрнең уртак тырышлыгына ориентирлашкан комплекслы якын килү нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

Авыл җирлегенең транспорт системасының үсешен планлаштырганда, тулаем алганда, районның һәм регионның транспорт системасының перспектив үсешен исәпкә алырга бик кирәк.

Авыл җирлегенең транспорт системасы регион транспорт системасының элементы булып тора, шуңа күрә, территориядәге транспорт инфраструктурасының оптимизациясе белән бәйле барлык мәсьәләләрнең чишелеше муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре кысаларында гына хәл итеlә алмый.

Транспорт инфраструктурасының үсеше буенча Программадагы (данные) тәкъдимнәр турындагы мәгълүматларны бюджеттагы барлык дәрәҗә катнашында гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.

Җирле үзидарә органнарының бурычлары дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча оешкан чаралар, Кама Тамагы районының җирле үзидарә органнарының һәм транспорт инфраструктурасы үсеше буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының инициативалы тәкъдимнәрен әзерләү булачак.

Федераль дәрәҗәдәге транспорт инфраструктурасы үсешенең төп юнәлешләре 2008 елның 22 ноябрендәге 1734–р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган, Россия Федерациясенең транспорт стратегиясе белән билгеләнгән.

Транспорт стратегиясе нигезендә транспорт системасы үсешенең стратегик максаты:
- сәләтле сыйфатлы транспорт хезмәтләрендә инновацион социаль юнәлешле икътисад һәм җәмгыять үсешенең ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Нәтиҗәле конкурент булырлык сәләтле транспорт системасы булдыру өчен өч төп нәрсә кирәк:

- Конкурент булырлык югары сыйфатлы транспорт хезмәтләре;
- Конкурент булырлык югары сыйфатлы транспорт хезмәтләре белән тәэмин итәрлек дәрәҗәдә кирәк булган югары дәрәҗәдә җитештерүчеле куркынычсыз транспорт инфраструктурасы һәм транспорт чаралары,
- Транспорт хезмәтләренең тәкъдим дәрәҗәсен ихтыяҗдан югары күтәрү өчен шартлар тудыру (югыйсә, конкурентлы мохит булмаячак).

**Муниципаль берәмлекнең транспорт комплексын үстерү өлешендәге чаралары**

| | | |
|---|---|---|
| Программа карарлары нигезендә муниципаль берәмлекнең торак пунктларында этаплап урамнарны төзү һәм төзекләндерү муниципаль максатчан программасын эшләү һәм кабул итү | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген автоюллар квалификациясе нигезендә раслау. | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Территорияләрне планлаштыру буенча документацияләрне эшләү белән комплекста хәл ителүче юл хәрәкәте иминлеге буенча чаралар комплексын эшләү һәм гамәлгә ашыру | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Торак пунктлары урамнарындагы каты өслекле юлны реконструкцияләү, ремонтлау, төзекләндерү | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Юлларны һәм тротуарларны комплекслы төзү | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Тукталыш мәйданчыкларын җиһазлар белән тәэмин итү һәм җәмәгать транспорты өчен павильоннар урнаштыру | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын инвентаризацияләүнең паспортлаштырылуын үткәрү, бүлеп бирелгән полосаны билгеләү, җирле әһәмияттәге автоюллар биләп торган җир участокларын регистрацияләү(теркәү) | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |
| Барлык автомобиль юлларындагы һәм җирлек урамнарындагы барлык инженерлык корылмаларының техник торышын бәяләү белән инвентаризацияләү, кичекмәстән кирәкле реконструкциянең яисә яңа төзелешнең срокларын һәм күләмнәрен билгеләү | Осинниковское авыл җирлеге | 2018-2030 |

**Урам-юл челтәрен оптимальләштерү**

Авыл җирлеге транспорт комплексын үстерүнең югарыда сыйфатланган приоритетлары (өстенлекләре) нигезендә, Программа проектында урам-юл челтәрен оптимальләштерү буенча түбәндәге чаралар каралган

Программа тарафыннан, нормативлар нигезендә, магистраль урам-юл челтәрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр бирелә.

Авыл торак пункты һәм авыл җирлеге чикләрендә урам челтәре параметрларының төп исәпләүләре "Шәһәр төзелеше, шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү" СП42.13330. 2011 нигезендә кабул ителә.

Урам-юл челтәре төзелеше нигезенә хәзерге заманда булган һәм планлаштырылган авыл районнары арасындагы элемтә санын арттыру һәм урам-юл челтәрен төбәкнең автоюл системасына кертү идеясе салынган.

Урамнар иерархиясе дәрәҗәсе нигезендә аларның һәрберсенең аркылы профиле үтәлгән булырга тиеш.

Генераль план проектында торак пунктның урамнарының һәм юлларының проектлаштырылачак аркылы профильләре китерелгән.

Текст составында китерелгән аркылы профильләр һәм төп чертежда китерелгән чишелеш схемалары, территория планлаштыру, юлларны проектлау буенча киләчәктә эшләр үткәргәндә, регламентлаучы нигезләмә буларак каралырга һәм тәгаенләнергә мөмкин.

Машина йөрү өчен каралган юл өлеше киңлеге, чишелеш типлары һәм хәрәкәтнең төп юнәлешләре үзгәрешсез калырга тиеш. Муниципаль берәмлекнең комплекслы транспорт схемасын әзерләгәндә, шушы аркылы профильләр һәм чишелеш схемалары корректлаштырылган булырга мөмкин.

Авыл урамнарының һәм юлларының классификациясе проектның график өлешендә чагылыш таба. ("Транспорт инфраструктурасы үстеше картасы" материалларны нигезләү буенча). Аркылы профильләр маркировкасы шул ук схемада китерелгән.

Яңа торак төзелеше районнарында урамнарны һәм юлларны проектлагангда, кызыл линиядәге урамнарның проекттагы киңлеге үтәлеше мөһим, ул киләчәктә, урамнарны киңәйтү максатыннан, җир участокларын тартып алу һәм капиталь төзелеш объектларын җимерү буенча кыйммәтле чаралар үткәрүдән коткарачак.

Проекттагы урамнар бу рельефта шулай итеп урнаштырылырга тиеш ки, норматив авышу үтәлү таләбе башкарылган булсын. Катлаулы геоморфологик факторлар булган шартларда, төп урамнарны проектлаштыруга һәм төзүгә аеруча игътибар итәргә кирәк.

**Тукталыш һәм транспортны озак вакыт саклау урыннарын оештыру**

Авыл җирлеге территориясендә автотранспортны саклау, нигездә, предприятие участокларыннан читтә һәм җирлектә яшәүчеләрнең йорт яны участокларында гамәлгә ашырыла.

Гараж-төзелеш кооперативлары җирлектә юк.

Киләчәктә, халыкның автомобильләр белән тәүмин ителүенең фаразланган артуы дәрәҗәсен исәпкә алып, иҗтимагый билгеләнештәге биналар янында тукталыш урыннары оештыруны алдан хәл итү мөһим.

Ведомство һәм йөк автомобильләре җирлекнең коммуналь-склад һәм агросәнәгать зонасында саклауда булачак дип күздә тотыла. Халыкның җиңел автомобильләрен

даими һәм вакытлыча саклау йорт яны участоклары чикләрендә булачак дип күздә тотыла.

Әлеге бүлек буенча үтәлеше мөһим чаралар:

1. Төзелеш өчен бүлеп бирелгән участокларда иҗтимагый билгеләнештәге биналарның проектлы сыйдырышлылыгы нигезендә, административ чаралар белән мөһим булган санда парковка урыннары җайланмаларын тәэмин итү.
2. Хезмәт күрсәтү объектлары янында автостоянкалар төзү (барлык вакыт аралыгында);
3. Иҗтимагый тукталыш урыны оештыру.

**Җәяүлеләр урамнары системасын төзү: мөмкинлекләре чикле затларны барьерсыз мохит белән тәэмин итү**

Экологик яктан чиста мохитка ярдәм итү өчен, зур булмаган өзек аралыгында корреспонденция өчен, торак пункт территориясендә, Программа җәяүле урамнар системасын күздә тота.

Җирлек Программасында аз хәрәкәтләнүче кешеләр төркеме өчен барьерсыз мохит булдыру күз алдында тотыла.

Бу максат белән, иҗтимагый биналарны проектлаганда, норматив авышлы пандусларны җайлау, тротуарларның югары дәрәҗәдәге өслек белән каплануы һәм барьерсыз мохит булдыруга караган барлык кирәкле чараларның үтәлүе таләп ителергә тиеш.

Әлеге бүлек буенча чаралар:

1. Күпчелек җәяүлеләр хәрәкәте өчен булган урамнар системасын формааштыру (исәпләү срогы – перспектива);
2. Төзүчеләр тарафыннан барьерсыз мохит булдыру буенча таләпләрнең үтәлешен административ чаралар ярдәмендә тәэмин итү. (барлык чорда, яки вакыт аралыгында).